| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |  | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 11 2020 ел № 321

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (11 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.9 пунктның «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» баганасындагы 3 пунктчасын «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 2.9 пунктның «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» баганасындагы 4 пунктчасын «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны интернет - ресурсында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (территориаль үсеш буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе — А.Ф. Хәйретдинов